# Равил Фәйзуллин шигырьләрендә
# дөнья сурәтенең чагылышы

**Татарстан Республикасы Чүпрәле Муниципаль районы «Иске Чүпрәле беренче номерлы гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе**



татар теле һәм әдәбияты укытучысы Миңзифа Абдулловна Тажетдинова



Равил Фәйзуллин үзенең беренче шигырьләрендә үк дөньяны матур итеп күрергә тели һәм иҗатының буеннан-буена шуңа ирешүнең юлларын эзли. Бу аның күп кенә шигырьләрендә чагыла. Нинди генә сәяси үзгәрешләр булуга да карамастан, үз намусына хыянәт итмәскә сүз бирә шагыйрь. Хисләрен сурәтләү чараларына, тропларга төреп, символлар артына яшереп әйтә.

*Язның һәр көне, сәгате*
*дөньяны ямьләләтә,*
*Бу яз көнне яшь булуың*
*бәхет бит икеләтә!*
(Яз, 21 б. )

**Тарих, заман, вакыт кебек мәңгелек төшенчәләр турында уйлана шагыйрь. Вакытның кадерен белергә чакыра.**

*Җилләр шатлык алып киләләр.*
*Җилләр картлык алып киләләр.*
*Җилләр диннәр алып киләләр.*
*Җилләр чирләр алып киләләр...*
*Җил – вакыт ул, белми тынычлык!*
*Җил тамырын кисәр кылыч юк!*
(Җил – вакыт ул)

**Р. Фәйзуллин параллелизмнарны бик еш куллана. “Килде заман” [390 б.] дүртьюллыгындагы җөмләләр арасында ул болай төзелгән:**

*Илдә – шом,*
*Җирдә – шым.*
*Гарип көй,*
*Сәрхуш моң...*

Шигырьдәге динамизм билгеле бер эзлеклелектә килгән атау җөмләләргә, ягъни атау җөмләле (номинатив) синтаксик бөтенгә нигезләнә. Эпитетлардан торган соңгы ике юл ассоциатив фикерләүне көчәйтә.

*Еллар, чорлар катлаулы ул,*
*Тарих үзе сиртмәле.*
*Бу дөньяда кемнәр булып,*
*Кемнәр генә китмәде!*
*...Сулыйсың икән, тормышның*
*көй-серен өйрән җирдә...*
(Карт һәм шагыйрь)

*Дөнья –*

*фидаи җаннарның*

*Януында тора!*

**Р.Фәйзуллин үткән мирасыбызны сакларга чакыра. Милли тарихыбызны, телебезне, динебезне онытмыйча саклау бабайлар алдында да изге бурычыбыз икәнлеген аңлата.**

*...Ышаныч һәм өмет күзе белән*
*гасырлардан*
*Карап тора кебек бабамнар*
(Эрмитажда йөрим, 33б. )

*Бүтән килмибез дип,*
*торып киткән утыргычны ватмыйк әле.*
*...Җимермик әле барысын!*
*Без бит кыргый түгел ләбаса.*
*Беренчеләр түгел дөньяда:*
*Беләбез яхшы-яманны,*
*Буыннарның әманәтен һәм өметен...*
(Бүтән килмибез дип,
торып киткән утыргычны ватмыйк әле, 88б.)

**Р.Фәйзуллин дөньяны матур итүдә әхлакый кыйммәтләрнең өстенлеген раслый.**

*Замана һәр буынга*

*куя олы эшләр.*

*Безгә –*

*Ныклык*

*һәм Матурлык!*

*Безнең иман –*

*Гуманизм!*

(Кешелек язына йөз төбәп барганда” [180–181б.])

**Халык шагыйре Равил Габдрахман улы Фәйзуллин, телебезнең камиллеген раслап, аны дөньяви әһәмиятле итә.**

# Әдәбият

1.Заһидиллина Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма / Д.Ф. Заһидуллина, М. И. Ибраһимов, В.Р. Әминева. – Казан: Мәгариф, 2005. – 111 б.

2. Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше: югары уку йортлары өчен дәреслек-кулланма. – Казан: КДУ, 1993. – 263 б.

3. Фәйзуллин Р.Г. Сайланма әсәрләр, ике томда. I том. – Казан: Татар. кит. Нәшр., 1992. – 415 б.

4. Фәйзуллин Р.Г. Сйланма әсәрләр. 5 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. –399 б.